## Мастер-класс

**Мастер классның темасы:** Татар халык бизәкләреннән брошка ясау.

**Максат:** милли традицияләребез нигезендә ятучы кыйммәтле, милли, әхлак сыйфатларын саклау;

**Бурычлар::**

-татар халкының милли киемнәре, татар милли бизәкләре турында мәгълүмат бирү, кызыксынуларын арттыру;

- милли киемнәребездә чәчәк, үсемлек орнаментлары турында төшенчә бирү;
- милли мәдәниятыбызга ихтирам һәм мәхәббәт хисе тәрбияләү;
- татар халык бизәк элементларын кулланып, брошка ясарга өйрәтү;

**Кирәкле материаллар:** өлге (шаблон), кайчы, клей, фитр һәм бархат тукыма, эләктермә, бизәкләр.

### Мастер- классның барышы

1.Кунакларны каршы алу, сәламләү.

Таң ата да кояш чыга,
Кояшны сәламли көн.
Саумы, Кояш, сүнмәс учак!
Әссәламегаләйкем!
Ачыйк бәхет ишекләрен,
Бәхетле булсын һәркем.
Әй кардәшләр, милләттәшләр,

Әссәламегаләйкем! Хәерле көн ! Исәнмесез, хөрмәтле кунакларыбыз! Безнең “Уңган куллар “ остаханәсенә рәхим итегез. Сезнең белән аралашу өчен мин сезгә бер табышмак тәкъдим итәм.

2. Теманы табышмак ярдәмендә ачыклау.

-Иртә язда бакчаны
Бизи кызыллы, сарылы патша кызы. (Лалә чәчәге).

3.Әңгәмә.

- Уйлап караганыгыз бармы лалә чәчәге нәрсәне аңлата соң?
- Байлыкны, җитеш тормышны, көчле мәхәббәтне.

-Лалә чәчәген без бакчадан тыш кайларда күрә алабыз? ( мәчет диварларында, кабер ташларында, Кол Шәриф мәчете тәрәзәләрендә, милли бизәк буларак татар хатын - кызларының, егетләрнең милли күлмәкләрендә, камзулларында, намазлыкларда, читекләрдә, калфакларда, түбәтәйләрдә, яулыкларда, ашяулыкларда һ б.)

-Лалә нәрсәне символлаштыра?

-Лалә-яңарыш чәчәге.Ул иртә язда беренче булып шытып чыга, җирне яңарта. Республикабызның туграсы(гербы)нда да лалә чәчәге ясалган. Димәк, Татарстанның көчле, нык, төрле яктан үсеш алган дәүләт булуын аның гербындагы лалә чәчәге дә күрсәтә.

-Әйе, лалә байлыкны, мәхәббәтне, тугрылыкны, матурлыкны аңлата. Шуңа да татар халкының декоратив сәнгатендә лалә чәчәге орнаменты бик зур урын алып тора.Лалә чәчәгеннән тыш яфраклар, кыңгырау чәчәк, роза чәчәге, дулкынлы, бормалы бизәкләр, әйләнмәләр, ярым түгәрәкле һ.б бик күп төрле бизәкләр күрәбез без тирә-ягыбызда.

Халкыбызда мондый хикмәтле сүләр бар:

**Сөйлә миңа- мин онытырмын, күрсәт – истә калдырымын, кызыксындыр- өйрәнермен** ” Хәзер без сезне татар халкының милли бизәкләреннән, бүгенге очрашуыбызның истәлеге булып калсын дип, брошка ясарга чакырабыз. Әлеге брошкаларныны түшкә кадыйлар.

Бу матурлыкны теләге булган һәр кеше ясый ала.

Сезнең алдыгызда яшел, шәмәхә, зәңгәр, алсу, сары, көрән төстәге милли бизәк элементлары. Яшел төс - яшәү билгесе, зәңгәр – тынычлык, күк йөзе, сары – кояш, алтынсу – затлылык төсе буларак сурәтләнә. Хәзер милли брошка ясау өчен өстәл янына рәхим итегез!

4. Брошка ясау.

5. Нәтиҗә ясау. Йомгаклап шуны әйтәсем килә, татар булуыбыз белән горурланыйк! Динебезне, телебезне, матурлыкны яраткан, яхшыны–яманнан аера белгән, гореф – гадәтләрне хөрмәт иткән балалар тәрбиялик.